ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1905**

«Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге 2389 номерлы карары белән расланган Гаилә мәктәпкәчә төркемнәр оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашырганда контроль чараларын үткәргәндә үтәлүе мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» 2020 елның 8 октябрендәге 1631 номерлы карарының 87 пунктына, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге «Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр » 2.4.3648-20 СП санитар кагыйдәләрен раслау турында» 28 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге «Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2389 номерлы карары белән расланган Гаилә мәктәпкәчә төркемнәр оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, атап әйткәндә, Нигезләмәнең 2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Гаилә мәктәпкәчә төркеме, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге «Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» 28 номерлы карары белән расланган «Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитария кагыйдәләре таләпләрен үтәп, балалар белән тәрбия-белем бирү процессын оештыру, туклану, йокы өчен мәйдан бүлеп бирелгән, күп балалы гаиләнең яшәү урыны буенча яки яшәү өчен буш торак урыннарда урнаша.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы-җитәкче урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев